РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр, пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 45 2026 елның 15 сентябре

«Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән гражданнарга бер мәртәбә акчалата бүләк билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе дәүләт бүләге - «Ата-Ана даны» ордены медале алган Түбән Кама муниципаль районында яшәүчеләрне бүләкләү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә яшәүче, «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка алучыларга) Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан 114 943 сум күләмендә бер мәртәбә акчалата бүләк билгеләргә.

2. “Ата-ана даны” ордены медале белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка алучыларга) бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибен расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә яшәүче, «Ата-ана даны» ордены медален алган ата-аналарга (уллыкка алучыларга) әлеге карар үз көченә кергән көннән соң түләнә дип билгеләргә.

4. Түбән Кама муниципаль районы бюджеты һәм финанслары департаментына ел саен Түбән Кама муниципаль районы бюджетын формалаштырганда әлеге карарның 1 пунктын үтәүгә бәйле чыгымнарны күздә тотарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарны җәмәгатьчелек белән элемтә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бүлегенә Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.И. Беляев

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2026 елның 15 сентябрендәге
45 номерлы карарына
кушымта

«Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән ата-аналарга
(уллыкка алучыларга) бер мәртәбә акчалата бүләк түләү
Тәртибе

1. «Ата – ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка алучыларга) бер мәртәбә акчалата бүләк Түбән Кама муниципаль районы территориясендә яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән ата-аналарның берсенә (уллыкка алучыларга) «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгәндә (алга таба-бер мәртәбә акчалата бүләк, мөрәҗәгать итүче) түләнә.

2. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алу өчен мөрәҗәгать итүче Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы адресына әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча гариза җибәрә.

Гаризага паспортның күчермәсе (2-3,5-12 битләр), шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы белән), мөрәҗәгать итүчене «Ата – ана даны» ордены медале белән бүләкләүне раслаучы документ күчермәсе, Россия Федерациясе Президенты указында күрсәтелгән белешмәләрендә мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, атасының исемендә үзгәрешләр булса, исемен үзгәртү турында мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, атасының исеме турындагы паспортында күрсәтелгән күрсәткечләрдән аерылса ЗАГС органнары тарафыннан бирелгән таныклыкның күчермәсе кушымта итеп бирелә.

3. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алу турындагы гариза теркәлгән көннән алып 14 календарь көн эчендә карала.

4. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алу турындагы гаризаны канәгатьләндерүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

әлеге Тәртипнең 1 пунктының таләпләренә мөрәҗәгать итүче затның гаризасы туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмавы;

тапшырылган документларда өстәмәләр, сызылган сүзләр, башка төзәтүләр һәм факттагы хаталар булуы;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган бер мәртәбә акчалата бүләк алган затның гаризасы белән кабат мөрәҗәгать итүе;

Түбән Кама муниципаль районының әлеге бүләкләү чарасын билгеләүче вәкиллекле органы карары үз көченә кергәнче «Ата – ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате.

5. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алу турындагы гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә мөрәҗәгать итүчегә аны кабул иткән көннән алып 14 көн эчендә җибәрелә.

6. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алу турындагы гаризаны канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, акчалар Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган банк счеты реквизитларына гаризада күрсәтелгән бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкне алу өчен уңай карар кабул ителгән көннән алып 14 календарь көн эчендә күчерелә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В. Умников

«Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән
ата-аналарга(уллыкка алучыларга) бер мәртәбә акчалата бүләк түләү Тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башлыгына
гражданнан________________________________
(Ф.И.О сы (соңгысы булган очракта))
паспорты __________________________________
__________________________________________,
теркәлгән адресы буенча:
__________________________________________,
телефоны: ____________________________,

Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк алуга
ГАРИЗА

«Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән ата-ана (уллыкка алучы) сыйфатында буларак бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне тапшыруыгызны сорыйм.

Бер тапкыр акчалата түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкаруыгызны сорыйм:

| | |
|---|---|
| счет номеры | ______________________________ |
| банк исеме | ______________________________ |
| банкның корреспондент счеты | ______________________________ |
| БИК | ______________________________ |
| ИНН | ______________________________ |
| КПП | ______________________________ |

Гаризага түбәндәге документлар теркәп куям:

1. Паспортның күчермәсе (2-3, 5-12 битләр);
2. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
3. Мөрәҗәгать итүчене «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләүне раслый торган документның күчермәсе;
4. ______________________________________________.

«___» ___________202____ ел ________________________________
(имзасы, фамилиясе, инициаллары)

«Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән
ата-аналарга(уллыкка алучыларга) бер мәртәбә
акчалата бүләк түләү Тәртибенә 2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин, ______________________________________________________________

(Ф.И.О сы (соңгысы булган очракта))

шәхесне таныклаучы документ: _____________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________

(документ төре, сериясе, номеры, документны бирү датасы, биргән органның исеме)

адрес буенча теркәлгән: _____________________________________________

________________________________________________________________________

түбәндәге санап үтелгән шәхси мәгълүмат категорияләренә генә кагыла торган шәхси мәгълүматларымны: фамилиям, исемем, әтиемнең исеме; җенесем; туу датасы; шәхес итеп таныклаучы документ төре; шәхес итеп таныклаучы документ белешмәләре; гражданлыгым; бүләкләүләр турында белешмәләр; банк счеты турында белешмәләр эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Шәхси мәгълүматларны бары тик минем документларны карау максатларында гына куллануга, шулай ук әлеге нәтиҗәләр турындагы мәгълүматларны электрон чыганакларда саклауга ризалык бирәм.

Әлеге ризалык минем тарафтан югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле шәхси мәгълүматларыма карата гамәлләремне гамәлгә ашыруга, шул исәптән югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле, җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, өченче затларга мәгълүмат алмашу гамәлләрен гамәлгә ашыру, аларны ярлыландыруны, шәхси мәгълүматларны блоклауны, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган теләсә нинди башка гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә.

Мәгълүматлар алучының минем шәхси мәгълүматларны, автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылган ысуллар нигезендә, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә эшкәртүне гарантияләве хакында миңа хәбәр ителде.

Әлеге ризалык шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешкәнче яки мәгълүматны саклау срогы дәвамында гамәлдә була.

Әлеге ризалык теләсә кайсы вакытта минем язма белдерүем буенча кире алынырга мөмкин.

Ризалык биреп, мин үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш иткәнемне раслыйм.

«___» ____________202____ ел.                /______________________/ ______________

(Имзасы)                (Ф.И.Осы)